ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Җирләрнең һәм җир кишәрлекләренең хокукый режимы, аларның теге яисә бу җир категориясенә керүеннән һәм рөхсәт ителгән файдалануыннан чыгып, федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

2) 12 статьяның 7 пунктындагы 1 пунктчасында «бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү» сүзләрен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнүе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 32 статьяның 3 пунктындагы 1 пунктчасында «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;

4) $32^1$ статьяда:

а) 2 пунктта «бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен үзләренә җир кишәрлеге бирү йә мондый гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен үзләренә җир кишәрлеге бирү йә мондый гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлеген» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктның беренче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

г) 10 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

д) 11 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

е) 12 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 76-ТРЗ